*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Трагедия жанры турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. Мисаллар китерегез. (6 балл)**

**Җавап:** Трагедия – персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән һәм гадәттә фаҗига белән тәмамлана торган драматик жанр. Гуманистик идеаллар хакына көрәшә торган герой, көчле газаплануларга карамастан, үзеннән олырак көчләрне җиңеп чыга алмый; үзенең көчсез булуын, үлем алдында торуын белгәндә дә, трагик герой ирек, азатлык, дөреслек, мәхәббәт өчен көрәшә. Трагедиядә үткән тарихка бәйле җитди тема күтәрелә, монологлар күп була, күтәренке купшы стиль белән фаҗигалелек бергә үрелеп бара.

Мисаллар: Гаяз Исхакыйның “Зөләйха”, Фәтхи Бурнашның “Таһир–Зөһрә”, Нәкый Исәнбәтнең “Идегәй”, Нурихан Фәттахның “Кол Гали” һ.б.

**2. Фоторәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча эшләнгән? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (6 балл)**



**Җавап:** Г. Камал. “Беренче театр”

Геройлар: Хәмзә бай, Вәли, Гафифә, Хәбибрахман, Факиһә, Биби, Фатих.

**3. Алтын Урда чоры әдәбияты кайсы гасырны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) XIII йөзнең урталарыннан алып XV гасырның ахырлары

ә) XV гасыр урталарыннан башлап XVI гасырлар

б) XV гасыр урталарыннан XVII гасыр урталарына кадәр

**Җавап:** а) XIII йөзнең урталарыннан алып XV гасырның ахырлары

**4. XIX гасыр әдәбияты драматургын билгеләгез. (2 балл)**

а) Шәриф Хөсәенов

ә) Габдрахман Ильяси

б) Кәрим Тинчурин

**Җавап:** ә) Габдрахман Ильяси

**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын языгыз. (6 балл)**

а) «Хәят» _____________________ ___________________

ә) «Ана догасы» ____________________ __________________

б) «Әниемнең ак күлмәге» ____________________ ___________________

**Җавап:**

а) «Хәят» Фатих Әмирхан повесть

ә) «Ана догасы» Габдулла Тукай шигырь

б) «Әниемнең ак күлмәге» Шәриф Хөсәенов драма

**6. Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз (8 балл)**



1) ____________________________

2) ____________________________

3) ____________________________

**Җавап:**

1) Галимҗан Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Башкортстанның Солтанморат авылында мулла гаиләсендә туа.

2) Әдип төрле җирләрдә – Казахстанда, Уфада, Оренбургта, Әстерханда, Киевта яши, укытучылык итә, иҗат эше белән шөгыльләнә.

3) Галимҗан Ибраһимовның “Алмачуар”, “Табигать балалары”, “Көтүчеләр”, “Диңгездә” исемле хикәяләре, “Кызыл чәчәкләр” повесте, “Яшь йөрәкләр”, “Казакъ кызы”, “Безнең көннәр”, “Тирән тамырлар” кебек күләмле романнары бар.

**7. Шигырьнең исемен, авторын языгыз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгеләгез. (5 балл)**

Малай туды безнең. Нинди шатлык!
Икебезгә уртак бәхет таптык.

Сокланабыз аңа исебез китеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Егет үстерәбез туган илгә,
Мондый асыл малай бездә генә,
Тирбәтәбез йоклаганын көтеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Затлы кием, ефәк аңа гына,
Тәмле-татлы нәрсә тамагына;
Тәпи йөри башлый яңа гына,
Тып-тып итеп, тып-тып итеп.

**Җавап:** Гамил Афзал. “Өф-өф итеп”.
Хис- кичерешләр – шатлану, куану, көенү, кайгыру.

**8. Бала чагында алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да өйрәтә алмас, диләр. Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**